ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛ ГЫЙНВАР * 2021 * КАЗАН

1

Игорь КИЙКО



Доктор, мине ниндидер сәер тойгы борчый: читтән торып эшләвемне нәчәлнигем күзәтә кебек...



Рашат НИЗАМИ

ШИГЪРИ ШАРЖЛАР

• • •

Тәлгать Галиуллинга

Тәнкыйть дисәң – бик чамасын белеп,
Чагып-чагып селти кычыткәнны!
Моңа бер дә гаҗәпләнәсе юк:
Туган авылы чөнки – Кычытканлы.

• • •

Равил Фәйзуллинга

Сиксәненә таба авышса да,
һаман эштә, һаман хезмәттә.
Татарстаныбыз күлләрендә
Колач салып тагын йөзмәктә.

• • •

Разил Вәлиевкә

Аккош, Чуртан, Кысла – өчесе тиң
Күр! Өч якка тарта арбаны...
Ә Рәзилнең ун кешелек гамьне –
Милләт йөген тартып барганы.

• • •

Аяз Гыйләҗевка

Кайберәүләр кызыл сүз ярата,
Йөри, сайрый – акыл өләшеп.
Милли хисне тирәнәйтү өчен
Житми кайчак Аяз Гыйләҗев...

• • •

Ринат Мөхәммәдиевкә

Буе-сыны, күрче, аршынлыдыр,
Кылган гамәлләре – колачлы:
Мәскәүләргә тикле барып житеп,
"Татар дөньясы"на* юл ачты.

• • •

Зиннур Мансуровка

Тукай белән "тере" сөйләшүгә
Жөрьәт итәр икән кем тагын? –
Шагыйрь белән бергәләшеп әнә
Чыгардылар милләт Китабын.**

• • •

Нәҗибә Сафинага

Әгъләменнән*** алып калды бугай
Шигъри сүзнең көчен, өммәтен.
Алгы якка – Кояш тарафына
Этәрмәкче була милләтен...

• • •

Рәдиф Сәгъдигә

Әкияттәге батыр егет белән
Чагыштырып идем мин аны.
Әһле каләм һәм дә ап-ак кәгазь –
Аның язмышыдыр, иманы.

* "Татар дөньясы" газетасына нигез салды.
** "Тукай белән әңгәмәләр". ТКН., 2014 ел.
*** Шагыйрь Мөдәррис Әгъләм күздә тотыла.

Сергей ЕРМИЛОВ





ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Менә инде бер ел коронавирус дигән зәхмәт белән яшибез. Ниләр генә күрмәдек без: маскаларны да, өйдән чыкмыйча утыруны, полиция рейдларын, тулган хастаханәләрне, дарулар житмәвен дә... һәм бу афәтнең әлегә очы-кырые күренми. Күптән түгел хәтта Германиядә дә ил тарихында иң каты карантин керткәннәр: 10 гыйнварга кадәр анда мәктәпләр, кибетләр, ресторан, клублар ябыла икән. Нәрсә, немесләр быел яраткан Раштуа бәйрәмнәреннән дә колак кагалармыни инде?

Р. ГАРИПОВ

ЯШЕЛ ҮЗӘН

– Немесләре Раштуадан башка берәр ничек түзәр, ә менә аларның күпсанлы кунаклары Корбан бәйрәмендә нишләр икән? – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Яхшы табиб һәрвакыт пациентлары турында уйлаган кебек, сәясәтче дә һәрвакыт сайлаулар турында уйлый.

Дәүләт кешесенә кайчагында ахмаклыклар эшләү яраса да, ахмак нәрсәләр сөйләү беркайчан да килешми.

Акыллы кеше бөтен ялгышларны да үзе эшләми — башкаларга да мөмкинлек калдыра.

Сәясәт ул – колбаса шикелле: аның нәрсәдән һәм ничек ясалганын күрмәү хәерлерәк.

Елгада һәм хөкүмәттә иң җиңел нәрсә калкып чыга.

Әгәр дә хөкүмәт сезгә бөтен теләгән нәрсәгезне бирерлек дәрәҗәдә көчле икән, димәк, анда сезнең бөтен булган нәрсәгезне алырлык көч бар.

Хаклык табуга караганда, хата табу җиңелрәк.

Әгәр шикләнәсең икән, дөресен әйт.

(сәясәт белгечләре мәҗлесендә язып алынды)

Уңышлы көн

Рөстәм ХАЛИТОВ

Эшкә килеп җитәргә өлгермәдем, мине хезмәттәшләрем чолгап алды. Элек алар миңа игътибар да итмиләр иде, ә хәзер кулымны кысудан бушамыйлар, хәлләремне сорыйлар, гаиләм турында... Шунда яныма Сәмигуллин да килде, кыенсынып кына кулыма акча төртте.

– Ни өчен? – мәйтәм.

– Хәтерлисеңме, үткән ел синнән бурычка алган идем. Менә кайтарам... – диде ул моңсуланып.

Дөресен әйткәндә, мин аның бурычы барлыгын оныткан идем дә инде.

Төшке ял вакытында барысы да минем сөйләгән мәзәкләремнән күзләреннән яшь чыкканчы көлделәр, менә – тәгәри-тәгәри... Әллә ни кызык та түгел иде бугай инде ул мәзәкләр.

Озак та үтми, миңа калтыранган тавышы белән начальнигым шалтыратты. Үткән елгы проектымны вакытында карый алмавына гафу үтенде. Әмма ул проект тиз арада тормышка ашырылачагына ышандырды, һәм мин әле шактый гына зур премиягә лаек булачагымны әйтте, хезмәтем буенча югарыга күтәреләчәгемне белдерде.

Эш көне ахырында мине кадрлар бүлегенә чакырдылар.

– Сезнең ялыгызны декабрь аеннан июльгә күчерербез, – диделәр. – Гафу итүегезне сорыйбыз, бу турыда алданрак әйтә алмадык, – дип үтенделәр.

Чын күңелемнән аларны кызганып куйдым, чөнки кулыма шәһәрдән ерак түгел бер ял йортына юллама тоттырдылар. Кадрлар җитәкчесе бик озак үзләренең бу юнәлештә җитешсезлекләрен алга таба бетерәчәкләрен, төзәтәчәкләрен сөйләгәч, Сочига бирә алмаганына гафу үтенде.

– Талантлы кеше анда барырга лаеклы, – дип, кыюсызланып әйтеп куйды.

Өйгә мине шефның эш машинасында озаттылар. Кайтып, диванга авырга өлгермәдем, смартфоным аваз салды. Минем танышым Фәрхәд икән. "Ничек җаена килеп тора!" – дип уйлап алдым да, бүгенге уңышлы көнем турында сөйләргә тотындым.

– Ә син дөрестән дә бернәрсә белмисеңме әллә? – дип бүлдерде мине Фәрхәд.

Аның тавышында миннән көлгән сыман тойгы сиздем.

– Юк, белмим, ә нәрсә?

– Әтиеңнең энесе Сәлим турында?

– Мин аны күптән күргәнем юк... Исән-сау микән? – дип куркып куйдым. – Эшләре әйбәт микән?

– Көткәннән дә яхшырак. Аны министр итеп билгеләгәннәр.





Гаделлек кенә БУЛСЫН...

Бөтен дөньяда акча эшләү ысулы буларак, судлашу күптән инде гадәти күренешкә әйләнде. Дәгъваларны төрле сәбәпләр белән төрле рухи газаплар кичергән өчен күп миллионлы компенсацияләр таләп итеп, кешеләр берберсенә, зур компанияләргә каршы, хәтта би-ик өскә дә бирәләр. Һәм иң гаҗәбе шул – күп очракта теләкләренә ирешәләр...

Без бөтендөнья юнәлешләренә соңрак кушылдык шул – башта, гадәттәгечә, рәнҗетүченең ипи шүрлегенә менеп төшү яисә билгеле адрес буенча җибәрү белән чикләндек. Һәм шуның белән низаг хәл ителгән булып санала иде. Тик соңгы вакытларда хокук дәүләтенең тәмен тойган гражданнар гадәти булмаган дәгъвалар белән судка ешрак мөрәҗәгать итәләр. Максат шул ук – җан газапларын кыштырдап торган кәгазь кисәкләренә әверелдерү.

Санкт-Петербургта алданган ир хатынының сөяркәсен судка биргән.

– Өйдәге гаугалар аркасында минем хезмәт җитештерүчәнлегем төште, күп кенә әхлакый һәм рухи югалтуларга дучар булдым, – дип зарланган ул судта һәм кайнар канлы егеттән компенсация сыйфатында 150 мең сум таләп иткән. Ләкин суд сөяркәгә бармак янау белән чикләнгән, ә гаиләгә мөнәсәбәтләрен үзләренә хәл итәргә тәкъдим иткән.

Ә менә Мәскәүдә бер ир белән хатын аерылышырга карар кылганнар. Тик фатир, савыт-саба, йә мәчене түгел, ә инстаграм-аккаунтны бүләргә булганнар. Иҗтимагый челтәрдәге бит өстендә алар бергә эшләгәннәр, һәм ул аларга аена 300 мең табыш китереп торган. Бу мәсьәләне алар тату гына хәл итә алмагач, судка мөрәҗәгать иткәннәр. Хәзер виртуаль милекне бүлү белән район судьясына шөгыльләнергә туры киләчәк.

Тагын бер Мәскәү судына ботинкалар бүләргә туры килгән. Ике бертуган ерак 90 нчы елларда, икәү кушылып, 320 меңгә данлыклы брендның коллекциясеннән бер пар "фирменный" кара ботинка сатып алган булганнар. Бергә файдаланганнар – чиратлашып, аларны киеп кызлар янына йөргәннәр. Еллар узу белән аяк киеме раритетка әверелгән, һәм аның хакы миллионга җиткән. Бертуганнарның берсе мыштым гына аны сатарга булган. Икенчесе ризасызлык белдергәч, эш судка барып җиткән. Судның карары кыска булган – йә һәр туганга берәр ботинка, йә сатып, акчасын урталай бүләргә.

Татарстанлылыр да замана шаукымыннан артта калышмый. Бер утә кыю Казан кешесе иң изге сызыкны атлап чыгып, Россия президентын судка биргән. Илдәге катлаулы икътисадый хәл өчен ул Илбашыннан мораль компенсация сораган – шәп йорт, мунча, иномарка һәм бөтен кредитларын каплауны. Өстәвенә, әле хатыны белән балаларын кайтаруны да таләп иткән – аларның китүендә дә ул президентны гаепле тапкан...

Ә менә Совет районының мировой судьясына сихерчелек турында эш карарга туры килгән. Утырыш барышында бер хатынның ниндидер орлыклар сибеп, нәрсәдер пышылдап утыруын күреп, суд приставы шайтан илчесенә ау оештырырга булган...

Алабуга судында сыер кыйнау турында эш каралган. Берәү күршесен терлегенә бернича тапкыр сугуда гаепләгән. Имеш, шуның нәтиҗәсендә сыер көчле рухи тетрәнү кичергән һәм сөт бирми башлаган. Ә күршесе исә хайван казларымны куып йөри, шуңа күрә ул тиешен алды, дип белдергән.

Күргәнебезчә, үзләренең тормыш катлаулыкларын закон ярдәмендә хәл итәргә теләүчеләр арткannан-арта бара. Ләкин, чит илдәге коллегаларыннан аермалы буларак, безнең хөкем әһелләре рухи зыян күрүчеләргә акча өләшергә ашкынып тормыйлар. Дәгъвачыларга еш кына бернинди дә әҗер тәтеми. Бәлки, ул шулай булырга тиештер дә. Безгә, акчасыз яшәргә өйрәнгән халыкка, гаделлеге дә бик җитә...

Людмила САФИУЛЛИНА



Сергей АНДРИАНОВ

Эльвира ДЫШАЕВА





Сергей ЕРМИЛОВ



• • •

Бәлки, тәм һәм ис тою югалмагандыр, бары тик ризык әзерләүчеләр кризис чорында ризык экономияләү максатыннан аңа тәмләткечләр кушуны киметкәнкәндер?

• • •

Базарда:

– Әйтегез әле, помидорларыгызның үзкыйммәте күпме тора?

– Бу коммерция сере! Сиңа дигән бәя картонга язып куелган!

• • •

Диплом алу ул – 1861 елда крепостной правоны бетерү шикелле. Син ирекле дә кебек, ләкин шуннан соң нишләргә кирәклеге турында бернәрсә дә белмисең.

• • •

– Минем элеккеге иремдә коронавирус бугай, ләкин ул аны белми.

– Нигә шулай уйлыйсың?

– Ул ис-тәм тоюын гына түгел, зәвыгын да җуйган. Мин аны кичә бер кыз белән күрдем – адәм көлкесе – чын карачкы.

• • •

Безне көн саен хәтәр 90 нчы еллар белән куркыталар, янәмәсе шул вакыт кабат әйләнеп кайтачак. Минемчә, юкка – бездә хәзер хәлләр шундый ки, ул 90 нчы еллар үзләре үк курка кайтырга!

• • •

Яшь кенә актёр театрга эшкә урнашырга килә дә, директор кабинетына керә, язу өстәле артына утырып, бик эре кыяфәттә өскә карап сүз башлый:

– Тәк, минем шарт мондый: айга йөз мең түлисез, Мәскәү үзәгеннән фатир һәм унлап спектакль. Гел баш рольләрне уйныйм.

Директор моңа бераз карап торганнан соң:

– Менә болай килешәбез: айга унике мең, Мәскәү кырыендагы берәр тулай торак бүлмәсеннән караватъ, утыз роль һәм массовка, – ди.

Яшь актёр, озак уйлап тормыйча җавабын бирә:

– Риза.

• • •

– Кайда эшлисең?

– ФСБда.

– Берәр кызык нәрсә сөйлә әле!

– Минем белән кызыксынасыңмы, әллә үзең турындамы?





БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Татарстандагы этләр бәхетле, чөнки алар-ның туган теле юк. Сәясәт аларның ирегэн тамчы да кыерсытмый.

Алмаз Хәмзин: Ялгышасың, Рашат дус, аларның туган теле бар – "Вау!" (Татарча шулай). Бер сүз өчен сине кем кыерсытып торсын?.. Шуңа күрә алар иркле дә. Бәйдәгесе бигрәк татар шикелле...

Р. Н.: TV каналларын да цифрлаштырып бетерделәр. И Ходаем, кешеләрне цифрлаштыра күрмәсеннәр!

А. Х.: Цифрлаштыру пүчтәк ул, менә маскаладылар, изоляцияләделәр, вирусладылар... Юк без хәзер, юк...

Р. Н.: "Зөләйха" романы авторы Гүзәл Яхина: "Мин әбиемнең күргән-сөйләгәннәрен яздым", – дип аклана. Димәк, әсәрдә тормышны, "фотографияләү" ысулы өстенлек алган, Юкса биредә милләтебезнең югары рухын, әхлагын сәнгати күрсәтү үзмаксат булырга тиеш иде.

А. Х.: Идеологиясе булмаган илдә мондый максатлар куелмый. Ә менә әсәр эчталегендә хакимнәр үзләренә яраклаштыру алымын оста кулланалар. Моңа романда җае чыгып торган сюжетлар байтак.

Р. Н.: Тугрылыкта этләр генә адәм белән ярыша ала.

А. Х. Бу мәсьәләдә өстенлек этләрдә. Чөнки эт чыннан да тугрылык белән эш йөртә, кеше – үзенә файда белән.

Р. Н.: Илдар Юзеев әйтер иде: "Исәнлек пүчтәк ул, сәламәтлек кирәк!" – дип.

А. Х.: ... һәм шулай да!..

Р. Н.: Космос формуласын, образлы итеп, берничә сүз белән әйтеп була: Кояш – Галәм чибәренең нурлы йөзе, йолдызлар – шул илаһи кыз йөзендәге сипкелләр, Ай – җиһанның сыңар алкасы...


А. Х.: Ә Рашат?.. Коньяк йолдызлыгының...

Р. Н.: Үзеңне тәнкыйтьләүгә караганда, кешене сүгү ансатрак.

А. Х.: Безнең җәмгыятьтә хәзер тәнкыйть тә, сүгү дә юк, бары тик сүгенү генә бар.



Валерий ТАРАСЕНКО



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Дамир МОРТАЗИН

Бозга таюдан чыккан фикер

Салкын көннәрнең берсендә, хатын белән кышның матурлыгына сокланып йөргәндә, каршыбызга Хәлим очрады. Нигәдер, аксый.

– Нәрсә булды? – дип сорадым мин аптырап.

– Менә сеңлем Кадриядән чыгып килгәндә, әнә тегендәге урам почмагында аягым таеп китте дә егылдым... – диде ул. – Анда бозлы җир, ә мин шуны уйлап тормыйча узып бара идем.

– Әйе шул, анда алагаем шугалак! Зоомагазин кырыенда, – дип төгәллек кертеп куйдым мин. – Беркайчан шуны чистартмыйлар. Гел зарланабыз югыйсә. Ичмасам, ком да сипмиләр.

– Юк, мин "Кулинария" янында егылдым бит. Анда зоомагазин күрмәдем лә...

– Ничек инде булмасын? – дип гаҗәпләндем мин.

– Ни... алар арасында ниндидер ызгыш чыгып, үзләренең кошлары, балыклары, әрләннәре белән китеп бардылар! Хәзер ул урында "Кулинария"...

– Сез икегез дә ялгышасыз, – дип бәхәскә хатын кысылды. – Чыннан да, анда элек зоомагазин иде, аннан соң "Кулинария" булды, ә хәзер "Вак-төяк" кибете ачтылар – мин аннан кер порошогы алдым акция буенча...

– Сөйләмәгез әле юк-барны, – дип әйтеп куйды Хәлим эче пошкандай. – Мин егылдым бит, сез түгел.

– Әлбәттә, син һәм бик нык – башыңдагы уйларың да шуңа күрә бутала башлаган...

– Андый чакта шулай булгалый, – дип әйтеп куәтләде хатыным. – Стресс барлыкка килгән...

– Борчылмагыз, башым менә дигән! – дигәндәй, һаман үзенекен кабатлады Хәлим. – Ә менә сезнеке...

Бик тирәнгә китте, ахрысы, бәхәсебез, шуңа күрә мин тыныч кына Хәлимгә тәкъдим керттем:

– Әйдә, узып-китеп баручылардан сорыйбыз. Бәлки, берәрсе дөресен әйтер...

Беренче булып бик зыялы кыяфәттәге әби кеше соравыбызга колак салды.

– Беләм мин ул урынны, беләм, анда әле "Әбибас" аяк киеме кибете бар иде, – дип сүзен башлады. – Мин инде андагы боз турында шикаять яздым...

– Син, нәрсә, кешеләрнең башын бутыйсың! – дигән ачулы караш белән бәхәскә күзлекле бер ир кеше килеп кушылды. – "Әбибас"ны контрафакт өчен яптылар, анда хәзер "Тиз акчалар" һәм тагын...

Ләкин аны хатыным бүлде:

– Нигә бәхәсләшәбез, әйдә интернеттан актарабыз, – һәм букчасыннан смартфонын чыгарды.

Бер минут та үтмәде, экранда, теге Хәлим егылган урында – "Соңгы юлга" дигән ритуаль контора урнашканлыгы мәгълүм булды.

– Ә бит мин аларның клиенты булырга бик мөмкин идем, – дип фәлсәфи фикер йөртеп, тирән уйга чумды Хәлим.

Зыялы әби башкачарак фикердә иде: "Бозланып каткан җәмгыятьтән барысын да көтәргә мөмкин..." – диде ул үзалдына, үзенең гомер тәҗрибәсеннән чыгып.

ҮГЕЗ ЕЛЫ

Гүзәл НӘБИУЛЛИНА

Яңа ел КОРПОРАТИВЫ

– Тәк, иптәшләр, шундый тәкъдим бар, – дип башлады фирма директоры Баев, "Карнавал" фильмындагы Огурцов кебек. – Яңа елны әйбәтләп каршылау турында карар чыгарылган, ләкин элекке еллардагы кебек шау-гөр килеп түгел, тыйнаграк итеп, сан ягыннан да кешеләрнең күп булуы килешмәс. Тирә-юньдә вирус мыжлап тора – бәлагә бата күрмик.

– Ничек, бал-маскарадсыз Яңа ел була димени? – дип пошынып куйды секретарь кыз Тәнзилә.

– Һмм... Бал-маскарад? Ә син беләсеңме үткән елгысы ничек булып беткәнен? Хәзергә хәтле битлекне салмыйбыз, тикшерәләр дә тикшерәләр... Авызыңны да ачма бу турыда. Берничнди маскарад ясамыйбыз.

– Быелгысы Күсе елы түгел бит, Үгезнеке, – дип, каршы килгәндәй әйтте секретарь.

– Менә шул-шул – Үгез елы! Үзеңнең иреңә мөгез куюың җитмәгән?!. Кабатлап әйтәм, берниндимаскарад кәчтүмнәре кимибез.

– Яхшы! – Инде бухгалтер Акчаров урыныннан купты. – Минем менә нинди тәкъдимем бар: әгәр инде күп кешеле корпоратив оештырырга ярамый икән, болай эшлибез... Һәркем Яңа елны үзенең фатирында каршы ала. Законга да сыя, ягъни изоляцияләнә.

– Бик әйбәт фикер бит бу, – диде директор. – Берочтан хезмәт хакы фондына да экономия! Шулай бит?..

Булды, килештек. Гаилә кочагында үткәрәбез. Ләкин һәрберегезнең скайплары эшләп торсын. Гаиләгез дә – каршыда, шул ук вакытта коллективта да кебек. Әмма өстәлдәге ризыклар барыбызныкы да бертөсле булсын. Бер-беребездән көнләшеп утырмыйк. Табынга нәрсә куясын беләсез – салатлар, кабымлыклар... Тагын бер мәртәбә ныклап кабатлыйм – берегездә дә маскарад кәчтүмнәре күрмим! Аңладыгызмы?

Тик кенә утыра белми бит секретарь Тәнзилә:

– Ә шампанс?..


– Скайпыңны сүндер...
















БЕЛЕМСЕЗ КАЛГАН КАДРЛАР

Нурлатта актив рәвештә "Демография" милли проектын тормышка ашырырга керешкәннәр. Шәһәрнең мәшгульлек үзәге һәм "Кадрлар әзерләү буенча региональ үзәк" дип аталган шәхси оешма 50 яшьтән узган 121 кешене укытып чыгару турында үзара ике миллионлык килешү төзегәннәр. Тыңлаучыларны җирле оешма һәм учреждениеләрдән җыйганнар. Ләкин менә укучыларның күбесе белем арттыруга мохтаҗ булмаган. Алар арасыннан 76 кеше, гомумән, мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итмәгән, ә кайберләре үзләренең "белем алулары" турында прокуратура хезмәткәрләреннән генә белгәннәр.

ТИРӘН ТАМЫРЛАР

Татарстанда киң тамыр җәйгән криминаль оешма табылган. Аның берничә ел дәвамында күчемсез милек белән эш иткәннәре ачыкланган. Аферalар оештыру белән "Заря-28" торак төзү кооперативы председателе җитәкчелек иткән, ә аның кул астында ТР Росреестры идарәсе башлыгы урынбасары һәм идарәнең бүлек башлыгы урынбасары, "Үзәк-коммуналь хезмәт" башлыгы урынбасары, риэлторлык компаниясе башлыгы, БТИ юрисконсульты һәм бер "браток" эшләгән. Оешманың төрле тармак вәкилләреннән торуына карамастан, эш бик төгәл һәм көйле алып барылган. Алар барлыгы 9 мәйдан җир, торак һәм торак булмаган биналарны шәхси милек сыйфатына күчергәннәр. Бу "эшчәнлек", нәтиҗәдә, 47 миллион сум һәм берничә җинаять статьясына тарткан.

ИРЕКСЕЗДӘН БИЗНЕСМЕН

Татарстанда яшәүче икенче группа инвалиды Татьяна М. көтмәгәндә үзенең Мәскәүдә алты автомобильле товар ташу фирма хуҗасы булуы турында белгән. Аңа почта аша юл кагыйдәләрен бозу һәм салымнар буенча бурычлар турында штрафлар килә башлаган. "Бизнесмен" ханымның түләнмәгән бурычлары ике миллион сум җыелган, ә табышлары бер тиенгә дә җитмәгән. Полиция, үзләренең бер көнлек фирмаларын бичара хатынга теркәгән аферистлар эше булганлыгын ачыклаган.

ЯЗМАГАН МЕҢНӘР

Казанда яшәүче Р. Интернетта законсыз төзелгән гаражларны сүтү турында мәгълүматка тап булган. Канында уйнаган эшмәкәрлек "оеткысы" егеткә монда акча эшләү мөмкинлеге турында хәбәр биргән. Ул, тиеш урынга тимер кисү һәм ташу бригадасы чакыртып, аны эшкә җиккән. Кискәләнгән гаражларны Р. металлоломга тапшырырга уйлаган. Ләкин моңа полицейскийлар комачаулаган. Туралган чит кеше милкенең бәясе 200 мең сум тәшкил иткән.







• • •

Безнең түләүсез медицинаның үзенчәлеге: кемдер акча белән түли, кемдер сәламәтлеге белән...

• • •

Түләүсез медицина авырулар акчаларын түләүле медицинага үз теләкләре белән бирсен өчен кирәк.

• • •

Түләүсез медицина соңгы сулышыңа кадәр дәвалый, ә түләүлесе — соңгы тиенеңә кадәр...

• • •

Мединституттан начар укыган өчен генә түгел, матур язган өчен дә куып чыгарулары мөмкин.

• • •

Акчаң булмаса, сәламәт бул!





• • •

Табиб йокысызлыктын интегүче фермердан сорый:

– Сез бер борынгы ысулны сынап карамадыгызмы?

– Нинди ысул ул?

– Ятасыз, күзләрегезне йомасыз һәм фермагыздагы сарыкларыгызны санап чыгасыз.

– Алай эшләп карадым инде, бер файдасы юк. – Хәтта киресенчә, тагын да начаррак йоклый башладым.

– Ничек инде?

– Утардагы сарыкларны санап чыгам, аларны вагоннарга төяп, ит комбинатына илтеп сатам. Шуннан соң бик арзан сатмадым микән, дип, таң атканчы аунап ятам.

Нәҗибә САФИНА

КИЛЕН КӨТКӘНДӘ

Ике күрше – кәнәфидә
иртәдән үк, никтер.
Берсе әйтеп куя
бер-ике сүз,
икенчесе генә
ишетми ничектер:

– Килен кирәк миңа,
күршекәем, ишет!
Арыдым дөнья көтеп.
Шул улымны әйтәм,
аптыратты инде,
булды тәмам өтек.

Яше җиткән,
ник өйләнми икән?
Әллә кызлар тапмый.
Әллә кайда йөри,
аңлый алмыйм,
таңсыз өйгә кайтмый.

Гел әзерне ашап,
күрәсең бит,
бетте симереп тә,
Арып беттем инде,
"килер елга"ларын
санап, чигереп тә.

Йокысыннан тора
ярты көндә!
Адәм тәганәсе...
Ашы пешкән,
өсте-башы юган.
Тагын ни әйтәсең.

Кыз карамас
түгел инде ансы.
Үзе карамыйдыр.
Хәзер кызлар
бигрәк бозык, ялкау –
улыма ярамыйдыр.

Төн буена гулять итә.
Төш җиткәнче
йоклап яталар шул.
Кайда йөриләрдер?
Таңда гына
кайтып яталар шул.
Өс-башлары
ташка үлчим инде, –
ертык-портык чалбар.
Ә мин өмет иткән булам,
бәлки, килен
улымныкын ямар.

Юк, кирәкми миңа
андый килен.
Кирәк чибәр, уңган.
Кулы ут уйнатсын,
теленнән бал тамсын,
таңда тора торган.

Дикъкать белән
күрше тыңлап торгач,
шулчак әйтеп куйды:
– Күршекәем,
әллә күрәзә син?
Укыйсыңмы уйны?
Минем кызым
нәкъ син көткән килен!
Әйдә ясыйк туйны!

Килен көткән әби
шып туктады,
телсез калды гүя:
– Шулмы килен? –
Тәмәкече кәнтәй,
ертык чалбар кия!

Чак һушына килеп,
әйтеп куйды:
– Керик инде, күрше.
Улым кайтыр,
аш куярга вакыт.
Кирәкми бер кеше.



Вячеслав ШИЛОВ



Александр КОСМЫЛИН



Валерий ТАРАСЕНКО



Ришат МИРЗАЯНОВ



АШЫЙСЫҺӘРВАКЫТ КИЛӘ

Бирән чире аркасында, Новосибирск шәһәренең полиция начальнигы Александр Гращенков өч елга шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм ителгән. Ул өч ел буе кафелардан ашау белән ришвәт алган. Өч эшмәкәр полицейскийны бушка ашаткан, шуның өчен тегесе аларны үз белдеклекләре белән муниципаль җирдә кафеларын урнаштырган өчен җаваплылыкка тартмаган. Шулай итеп, ул 53 мең сумлык ашаган. Үзара табыш китерә торган хезмәттәшлек, ашаучы һәм ашатучы як өчен дә җинаять эше белән тәмамланган.

ХАЛЫКТАН БАШКА

Башкортстанның Агыйдел шәһәренең мэры Фәнис Гыйльванов ихлас күңеленнән ни өчен аның якташлары вакантный урынга эшкә килмәүләрен аңлый алмый. «Мин аптырашта, агыйделлеләргә нинди эш кирәклеген аңлый алмыйм». Үзенең сорауларына ул шундук җавап алган. Шәһәрдә яшәүчеләр әйтүенчә, бөтен тәкъдим ителүче урыннарда хезмәт хакын аз түлиләр. Шуның өчен башка җиргә шабашкага барып эшләү яхшырак. Тегүче, электрик, автобус йөртүчеләрнең хезмәт хакы айга 6 меңнән 15 меңгә хәтле. Ә мэрның хезмәт хакы – аена 200 мең. Бу урынга бер кешедә бармыйча калмас иде.


МӨҺИМ ЯНДЫРУЧЫ

Яңа Мәскәү районының тикшерү бүлегенә өч ел элек ут төртү эше тәмамланып килә. Ул вакытта ике катлы бина янып бетә һәм ут бик күп җинаять эшләрен юк итә. Тикшерү барышында җинаятьнең заказчысы – мөһим эшләр буенча юстиция полковнигы булып чыга. «Мөһим» кеше үзенең начальнигын күрә алмаган һәм аннан үч алырга ниятләгән, янгыннан соң аны эштән алуларына өметләнгән.


ХӘЙЛӘЛЕ ЯЛ

Санкт-Петербургның полициясенә бер ир шалтыраткан һәм җанәрнеткеч хәл турында сөйләгән. Вакытны күңелле уздыру өчен, түбән социаль җаваплылыклы ике кыз чакырткан. Төн үткәргәннән соң, алар трансгендер булулары турында әйткәннәр. Аптырашта калган ир хезмәт өчен түләүдән баш тарткан. Ачулары чыккан кызлар клиентка борычлы баллоннан сиптергәннәр, ирләрчә тотып төйгәннәр, телефонын алганнар һәм куып чыгарганнар. Бу гендерлы конфликтны чишәр өчен, өчесен дә полиция бүлегенә алып киткәннәр.

Ринат АБЗАЛОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Мирзаһит тормышыннан

КЫЗЫКСЫНДЫРА БЕЛӘ

Авыл мәктәбендә чаңгы ярышы оештырырга булалар. Мирзаһит атна буе бәйгегә бертуган энесенең улы Рушанны әзерли: нәселне ким-хур итәргә ярамый бит.

Менә ярыш көне килеп җитә. Иң элек башлангыч сыйныфлар чыгыш ясый. Беренче булып директор малае Азат бара. Төркемнең койрыгында, иң соңгы булып энекәш малае сөйрәлеп килә. Читтән җанатарлар күзәтеп тора.

– Күрерсез әле менә, Азат беренче киләчәк. Йә икенче, ләкин соңгы булмаячак, – ди бер малай икенчесенә.

– Шулай инде, ул һәрвакыт беренче, – дип җавап бирә тегесе. – Ә менә Рушан финишка барып җитәр микән...

Мирзаһит, бу сүзләрне ишетеп, көч-хәл белән сөйрәлеп баручы Рушан янына йөгереп килә һәм аның колагына нидер пышылдый. Һәм шунда ышанмаслык хәл була. Рушан, йокыдан уянган кебек, кинәт башын күтәрә, күзләрендә очкын барлыкка килә, һәм ул, җанланып, алга таба элдертә. Ике минут эчендә барысын да узып китеп, финиш сызыгын кисеп уза һәм өенә таба оча.

– Нәрсә әйттең син аңа?! – дип сорый үз малае икенче генә булып килгәнгә кәефе кырылган директор.

– Әллә нәрсә түгел инде, – ди Мирзаһит. – Әбисе аңа яраткан бәрәңге сумсалары пешергәнен генә дип әйттем. Әхәт абыйсы кунакка килгән, сумсаларны ашап бетермәгәе, дидем...

– Кызыксындыра беләсең бит, Мирзаһит! – дип көлешә бөтенесе дә. Хәтта директор да елмаеп куя.

КҮҢЕЛ КУШУЫ БУЕНЧА

Әгәр авыл кибетендә шау-шу ишетсәң, бел дә тор: димәк, яңа ипи кайтарганнар. Бөтен авыл шунда җыелган.Сүз иярә – сүз, фикер алышу, бәхәс китә. Бу юлы мәктәп укытучыларының хезмәт хакы турында сүз чыга.

– Укытучыларга бик авыр туры килә, әлбәттә. Мондый хезмәт өчен күбрәк түләргә кирәк! – дип башлый Дания. – Бездә бит ничек: сайлауларда – укытучылар, концерт куярга булса – укытучылар, басуда чөгендер алырга да – алар...

– Ул балалар белән күпме нервы әрәм була, аның отчётлары гына ни тора бит! Аларның дәрәҗәсен үстерү өчен акча җәлләмәскә кирәк, безнең киләчәгебез – балалар алар кулына тапшырылган бит! – дип җөпли аның сүзен күршесе Нажия.

Ләкин башка фикер дә бар икән.

– Укытучылар, гомумән, акча турында уйларга тиеш түгел! – дип каршы төшә район депутатының хатыны Нәфисә. – Бу – үтә җаваплы профессия, һәм анда кешеләр җан кушуы буенча гына эшләргә тиеш! Акча юклыкка зарланып йөрергә түгел!

Чиратта Мирзаһит та тора икән.

– Алай булгач, илдәге халыкның күбесе җан кушуы буенча эшли инде, – ди ул. – Ә акча өчен чиновник-лар, депутатлар һәм банкирлар гына тир түгә...

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



КҮП ТЕЛ БЕЛҮ – ДӘРӘҖӘ!

Бер елны Рәсәй президенты Йошкар-Ола шәһәренә килгәч ясаган чыгышында рус телен өйрәнүне көчәйтергә кирәк, чөнки руслар дәүләт төзүче милләт диебрәк әйткән иде. Шуннан соң рус булмаган халыкларның туган теленә һөҗүм башланды, дип әйтергә мөмкин, шул исәптән, татар теленә дә. Татар теле дәресләре атнага ике сәгатькә генә калдырылды. Күп укытучыларга кыскартылу куркынычы янады, кайберләре башка профильле дәресләр укытырга яңадан хәзерлек үтәргә мәҗбүр булды. Югыйсә татар теле бит дөньядагы иң таралган 14 тел исемлегенә керә. Без үзбәк, казакъ, кыргыз, азәрбайҗан һәм башка төркиләр белән җиңел аралашабыз. Мәктәптә укыган елларда (1945–1953) 4 класс татарча гына укыдык. Инде 5 нче класстан төрле фәннәр керә башлады. Атнага икешәр сәгать немес һәм рус теле өйрәндек. Аларны югары белемле, сугыштан исән кайткан укытучылар укытты. Мәсәлән, рус теленнән грамматика һәм әдәбиятны өч тел белүче – Киргизов Степан. Ул чуаш иде. Безгә 24 битле дәфтәрне бөкләтеп, сүзлек ясатты. Рус телен татар теле аша өйрәтте. Алардан бердәнбер исән калган Зөлфия апа Шакирова (Әлки районы Төгәлбай авылы) немес телен укытты. Өч елда без рус, немес телен 80 процентка үзләштердек.


Күбрәк тел белү – әйбәт анысы, тик ана телен кыскарту хисабына булмасын иде. Бөтен гыйлем ана сөте белән керә, диләр бит. Хәзер шәһәр транспортында да игъланны өч телдә әйтәләр – русча, татарча, инглизчә. Шулай бер көнне 54 нче автобус белән елга портына барам. Автобус алай тыгыз түгел, әмма утырырга буш урыннар юк. Мин яшь түгел инде – 80 нән узган 2 нче төркем инвалид, аякларның хәле бетә торган чак. Шулай басып торам, янымда ике кыз, утырган килеш конспект укып баралар – студентлар, ахры. Үзләре немес сүзләре дә кыстыргалап сөйләшәләр. Салонда теге белдерү ишетелгәч, мин дә, өстәп, бер номер күрсәтим әле, дип, немесчә, русча, татарчаны кушып: "Их бине есть инвалидес цваен группен", – дип әйтеп куйдым. Мин дә инвалид, дигән сүз була инде бу. Шуннан теге кызларның берсе җәлт кенә сикереп торды да: "Дедуля инвалидес, битте!" – дип, миңа урын тәкъдим итте. Утырдым да: "Данке, дас медхен!" – дип әйтеп куйдым. Рәхмәт, кызым, дигән сүз инде монысы немесчә. Кызлар: "Гут, гут!" – дип кабатлады. Яхшы, яхшы – безнеңчә. Кайвакыт әз-мәз булса да чит тел белү ярап куя шул. Автобустагылар минем шаяртуны аңлап: "Вәт, инвалид бабай!" – дип шаркылдашып көлештеләр.

Сөләйман ШАКИРОВ

КАЗАН



Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 12, 1998



Айдар УТӘГӘНЕВ, «Чаян» № 18, 1996



• • •

Безнең илдә тиеш белемең булмаса, теләсә кайсы тармакта эшләргә мөмкин, ләкин тәҗрибәң булмаган килеш каравылчы итеп тә алмыйлар.

• • •

– Әйт әле, җаным, сиңа нинди хатыннар ошый: акыллыларымы, әллә чибәрләреме?

– Тегендиләре дә, мондыйлары да ошамый. Шуңа күрә мин сиңа өйләндем дә инде.

• • •

– Ни дисәң дә, хәзер яшәү җиңеләйде. Ә бит егерме ел элек телефонны унитазга төшерү өчен, башта аны стенадан өзеп алырга кирәк иде.

• • •

Әңгәмә барышында:

– Ә миңа кадәрге хезмәткәрегез кайда соң?

– Декретка китте.

– Куркыныч икән сездә...

• • •

ГАИ хезмәткәре машина йөртүчегә:

– Нигә салоныгызда аракы исе аңкып тора?

– Белмим, мин иртән ис сизмим.

– Хәерле юл сезгә. Юк, юк, правагыз һәм машина таныклыклары кирәкми!

• • •

– Беркайчан аңлап булмый бу хатын-кызларны: ничә яшьтә икәнен сорасаң, усалланалар, ә туган көннәрен онытсаң, чыгырларыннан чыгалар.

• • •

– Бүлмәмне ремонтлау өчен күпме алыр идегез?

– Егерме мең.

– Ә үзем дә ярдәм итсәм?

– Ул чакта кырык мең.

• • •

– Мин сиңа тыныч кына утырырга киңәш итәр идем.

– Нигә?

– Бер сүз дә әйтми утырсаң, сине ахмак дип уйлаулары мөмкин. Ә сөйләшә башласаң, бигрәк тә...



Вячеслав ШИЛОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



МУНЧАСЫЗ ЯШӘҮ

"Чаян" дус! Безнең Аксубайда мунча юк. Булган бердәнберен бернечә ел элек, планда каралган дип, япкан иделәр. Ә ул, һәрчактагы кебек, билгесез срокка сузылды...

Чабына-чабына мунча керүләрне бигрәк тә картлар сагынды. Аларның күпләре бит су үткәрелмәгән йортларда яши, үзләренең мунчалары беркайчан да булмаган, булган очракта да ягып керерлек хәлдә түгел.

Эшмәкәрләр бу очрактан оста файдаланып алдылар – бераз гына район үзәгендә коммерциягә корылган мунча эшләп алды. Бәясе хәтәр, бер сәгать юынып чыгу – 500 сум. Пенсия тиеннәрен чутлап караганнан соң, картлар, нишләргә белмичә, аптыраашта калды – чиста йөрергәме, әллә тукмы. Әлбәттә, ачтан үлеп, мунчага йөреп булмый.

Шулай да аксубайлылар җаен таба. Кемдер туганнарына бара, кайсыларыдыр үзәктәге спорткомплекс душында юына. Кайбер уңганнары күп фатирлы йортлары янында кечкенә генә мунча төзеп, эштерөштер булса да, юынып чыга. Ләкин боларына да тыныч тормыш юк, бу – муниципаль җир кишәрлеге буларак, "басып алучыларга" законсыз төзелешләрен сүтәргә кушалар...

Озакка сузылган мунча ремонтын тизләтү турында безнең үтенечләргә, җирле хакимият матур гына вәгъдәләр биреп юата. Үткән елны, мәсәлән, ремонтлап тормаячакларын, ләкин яңа юыну бинасы төзиячәкләрен һәм дә инде аңа урын тапканнарын да әйттеләр. Шатлыктан авызлары колакларына җиткән халык каен себеркеләре дә әзерләп куйган иде, ләкин булачак мунча урынында Класстан тыш эшләр үзәге калкып чыкты. Өметләрне тормышка ашыру якты киләчәккә күчерелде.

Бөтен инстанцияләргә киткән хатларыбыз түрәләрне инде туйдырып бетергәндер, аларны йомарлап мәгълүм савытларга ыргытканнардыр... Җитмәсә, ковид-пандемия килеп чыкты, алар өчен яңа аклану мөмкинлеге туды: инде күпме еллар эшләми торган мунча шул коронавирус аркасында ябылган булып чыкты. Санитар-эпидемиологик хәл рәтләнгәч, ачылачак икән. Ай-һай, әйбәтләнер микән ул, ярты бистә халкы юына алмый йөри бит...

Аксубай бистәсе халкы.



Михаила ЛАРИЧЕВ рәсемнәре



Аның музыкасы — халык җанында

Салих Сәйдәшевнең тууына — 120 ел



Бөек татар композиторы Салих Сәйдәшевнең тууына 120 ел булды. Ул – татарның беренче профессиональ композиторы һәм дирижёры, яңа жанр – татар музыкаль драма тудыручыларның берсе. Кәрим Тинчуринның "Зәңгәр шәл" легендар пьесасына язылган музыка халык тарафыннан әле дә яратып кабул ителә һәм зал тулы тамашачыларны җыя, ә инде данлыклы "Кызыл Армия маршы" Мәскәүдәге 1945 елгы Җиңү парадында яңгырый. Салих Сәйдәшев халкыбыз күңеленә музыкасы белән генә түгел, кешелеклелеге белән дә кереп калган. Тормышны сөюе, кыенлыкларга түзем булуы һәм тыйнаклыгы сокландыра. Менә композитор тормышыннан кайбер мизгелләр...

МУЗЫКАСЫНДА – ТУКАЙ ЧАГЫЛЫШЫ

Салих үскән йортта Габдулла Тукай еш булгалаган. Кайвакытта шагыйрь аларга йомышы төшмәсә дә, малайның уйнаганын тыңлап утыру өчен дә кергән. Чыгып киткәндә: "Яхшы да уйный инде, шельма! Музыкант булыр!" – дип, елмаеп әйтә торган булган. Хәтта бер матур гына риваять тә бар: янәсе Салихның гармунына чахотка белән авыручы Тукайның бер тамчы каны тамган. Менә шуннан кешеләр Сәйдәшевнең язмышын юраган – музыка өлкәсендә Тукай шигърияте кебек әһәмиятле, ләкин авыр кичерүләр аша үтәчәк...

ӘЙБӘТ ҖЫРЛАУ

"Зәңгәр шәл" репетицияләрен үткәргәндә композитор интегеп бетә торган булган. Драма артистларын оркестрга кушылып җырлату бик җиңел түгел икән. Күп мәртәбәләр бер үк мотивны җырлатса да, алар музыка авторының таләпләрен үти алмый. Шул чагында Сәйдәшев дирижёр таякчыгын пультка куя да, нота дәфтәрен ябып, болай дип әйтә торган була:

– Бик әйбәт җырладыгыз, хәзер миңа бераз ял итеп алырга мөмкинлек бирегез...

ИҢ КЫЙММӘТЛЕСЕ

"Зәңгәр шәл"дә Мәйсәрә ролен Рокыя Кушловская башкарган. Тамашачы аны озак алкышлаган, хәтта сәхнәдән чыгармыйча.

Спектакльдән соң Сәйдәшев, грим бүлмәсенә кереп, барлык артистларга рәхмәт белдергән. Ә Кушловская янына килеп:

– Рокыя ханым! Сез бүген үзегезнең гаҗәеп матур тавышыгыз белән минем музыканы тамашачыга җиткердегез, шуның өчен мин сезгә иң кадерле әйберемне бүләк итәм – әлеге спектакльдәге беренче ноталарны.

ОН МӘШӘКАТЕ

Сугыштан соңгы елларда, бәйрәм уңаеннан, кибетләргә он кайткан. Бер кулга – өч кило. Чират алыр өчен иртәнге өчтә торырга кирәк. Соңга калсаң – бернәрсә калмый.

Бервакыт казанлыларга мәгълүм Бутлеров урамындагы "Горняк" кибетенә керә Салих абый. Он инде сатылып беткән, яшь кенә сатучы кыз бушаган капчыкларны җыештырып йөри. Композитор кыяр-кыймас кына сорый:

– Кызым, бераз гына он калмадымы?

Сатучы, кисәк кенә үзгәреп, кычкырып әйтә: "Күзең чыккан мәллә, бетте бит!"

Бөек композитор – татар халкының горурлыгы – башын аска иеп, эндәшми-нитми кибеттән чыгып китә...

БИЛГЕСЕЗ БАЙ

Кәрим Тинчуринның "Җилкәнсезләр" пьесасында сүзсез уйный торган байлар персонажы бар. Бервакыт спектакль вакытында сәхнәдә берәүгә дә таныш булмаган "бай" барлыкка килә – сакаллы, мыеклы һәм алагаем корсаклы. Әйтерсең лә махсус симертелгән татар бае. Пьесада язылганча, барлык "бай", дога кылып, кайсы кая утырышкач, әлеге дә баягы "бай" каты итеп кикереп куя. Тамашачы көлүдән шартлый һәм кул чаба башлый. Аларга кушылып сәхнә артындагы артистлар да көлешә, ләкин кем шулай иткәнен аера алмыйлар. Пәрдә ябылгач, моның кем икәнен белергә теләп "байга" ябырылалар. Аларның бу "бай"ның сакалын куптаргандагы гаҗәпләнүләрен күрсәгез! Юан персонаж Салих Сәйдәшев икән бит...

АҢА НИ ҖИТМӘГӘН

Гомеренең соңгы елларында Сәйдәшев театрдан читләштерелә, ул төшенкелектә яши, аның музыкасы да спектакльләрдә яңгыратылмый. Көн саен диярлек ул театрга керә торган ишек янында басып тора башлый. Бервакыт аннан сорыйлар: ни өчен хәзер аның элеккеге кебек иҗади активлыгы юк? Боек кына елмаеп, Салих абый җавап кайтара: "Миңа Кәрим Тинчуриннар җитми..."

Халык, бернигә карамый, "үзенең Сәйдәшен" яратты. Ул халык күңеленең нечкә кылларын чиртүче, уятучы бердәнбер композитор иде. Бүтән берәү дә аның кебек булдырмаган! Бөек композиторны Габдулла Тукайны озаткан кебек, соңгы юлга озатканнар... Урамнар халык төркеме белән шыплап тулган булган... Аны җирләгәч тә, данлыклы Сәйдәш маршын уйнамыйча, берәү дә таралмаган...

Дусларча шарж
һәм композитор турында исталекләр
Иза Сәйдәшева тарафыннан бирелде.

Катнаш туйда

– Кызлар, кызлар, – диде алып баручы. – Мәҗлеснең иң матур җиренә килеп җиттек. Кемнең тизрәк кияүгә чыгасы килә... Кайсыгыз җитезрәк, кайсыгыз өлгеррәк икән? Карыйк әле. Туй букеты кайсыгызның йокы бүлмәсен бизәр икән? Әйдәгез әле, әйдә...

Йола буенча бу уенда, гадәттә, кияүгә чыкмаган кызлар гына катнаша. Шуны гына көткән кебек, унлап чибәр урыннарыннан кузгалып, бию мәйданчыгына таба юнәлде. Бер ел элек ирсез калган Галия кодагый да, нигәдер, аларга иярде. Болай, шаярып кына чыга торгандыр дип уйлаган идек. Ләкин ул үтә бер җитезлек белән килен букетын эләктереп алгач, гаҗәпләнүебез бермә-бер артты. Дәшми генә утырган хатыннарның да авызлары ачылды:

– Какая шустрая татарка.

– Нәрсәгә инде ул аңа...

– Яшьләрнең күз яше төшәр, ыргыт...

– Базар хатынының кулыннан алырсың бушлай әйбер, туганына да сатып бирә бит ул тауарын, – диештеләр кодагыйны белгән апалар.

–Чәчәген ала алдым, хәзер кияү генә табасы калды, – дип шаяргандай булды.

Татарча аңлаганнар көлешеп куйды.

Буйдак егетләргә кагылышлысы да бар икән бит әле йоланың. Бик күп туйларда булсам да, мондыен ук күргәнем юк иде.

Монысы хохол кияүнең эше булып чыкты. Ул киленне барыбызга да ачык итеп күренерлек урынга бастырды. Уң аягын күтәреп урындыкка куйды, аннары кәләше алдында тезләнеп, куллары белән аның туй күлмәге астына кереп китте. Тегесе, анда ни барын без дә күрсен диптер инде, күлмәк итәген кендегенә таба сыдырып менгерде. Челтәрле ап-ак нәфис эчке киемнәр, тулышып торган яшь дәртле тән алгы планга чыкты...

Хохол кияү тарттырып киелгән "подвеска" дигән нәмәрсәкәйне бик озак итеп, бик тәмләп салдырды. Аннары бер төркем егетләр алдына чыгып, кинәт кенә кулларын селтәп җибәрде, ләкин теге ак әйберне ыргытмады. Яшьләр сикерешеп куйды, гөрләшеп-көлешеп алды. Залда янә тынлык урнашты...

Бөтен кешенең күзе шунда гына иде, дисәм, юк икән... Кузьма дәдәйнең аларда гаме юк кебек. Карашларында нур әсәре күренми. Бер хәрәкәтсез калып, табынга карап утыра да утыра. Аның өчен дөньяда тагын да "тәмлерәк" нәрсәкәйләр бар икән шул. Кунаклар хохол кияүнең кәләш күлмәге тирәсендә мыштырдаганын күзәткән арада, берьюлы ике рюмка йотып куярга өлгерә. Аннары рәссам ясаган портрет сыман катып кала. Ник бер җире селкенсен дә, ник бер керфеге кыймылдасын...

Яшьләрнең гүзәллегенә сокланып утырган хатын, борылып, иренә нидер әйтмәкче иде, әмма аның балкыган йөзендәге нурлар бик тиз сүнде, кашлары җыерылды.

– Салдыңмыни? – дип сорады ул Кузьма дәдәйдән. Аннары, җавап та көтмичә:

– Их син, җир бит! Мин бит сине, коймa буенда ятып сөрсегән адәмне, кешеләр арасына алып чыкмакчы идем, аралашсын, төзәлсен, димәкче идем... Әй... Аннары, әйтеп-аңлатып торудан ни файда дигәндәй, иренә яны беләнрәк борылып, табынга текәлде, күзенә чалынган беренче рюмканы эләктереп, үзе дә салып куйды.

– Күршеләреңә кара әнә, – диде ул бераз тын алгач, баш бармагы белән генә күрсәтеп. – Әнә ничек итеп матур киенгәннәр, ак күлмәктән, галстуклардан... әнә ничек матур итеп ашап-эчеп, гәпләшеп утыралар. Әллә минем шулар кебек дөньямны онытып бер ял итәсем килмиме, әллә минем...

Чыннан да, тегеләр килештереп утыра беләләр иде. Иренең хатынының тәлинкәсенә тегесен-монысын алып салуы, ирен тидереп куйган рюмкасын әледән-әле шәраб белән тутырып торуы бер аларның гына игътибарын җәлеп итмәгәндер. Әйе. Ул хатын мондый хөрмәткә лаек иде, бик лаек, чөнки сигез ел буе көтте бит ул иренең "тегеннән" кайтканын, сигез ел... Сәбәбен дә әллә кайдан эзлисе юк. Шул катнаш туйда яшьләр арасында чыккан низагтан гына...

Без тәнәфес игълан иткәнне көтеп тормыйча, әкрен генә урыныбыздан кузгалдык. Туй мәҗлесе иң биек ноктасына җитеп, студентларның тулай торагында барган дискотеканы хәтерләтеп гөрли калды.

Такси озак көттермәде. Юлда кайтканда да мин катнаш туйларларның уңай-тискәре яклары турында уйланып кайттым. Гыйбрәт алырлыклары да байтак. Шулай да үз милләт кешең белән тормыш коруга ни җитә. Менә шуны яшьләргә аңлатып кара син...

Күңелгә авыр булып калганы әле дә күз алдымда. Туганнан туганым Таһирның туе иде ул. Беренчедән, аның бер кимчелеге бар – тотлыгып сөйләшә. Икенчесе, урыс кызы белән танышуы. Аның: "Д-д-д-а-й по-по-по-жалысты"сын көткәнче ярты сәгать үтә. Әле урысча сөйләшә белсә – бер хәл. Алар ничек аңлашадыр, белмим.

Туйның күңелгә тигән мәле шул: гөрләп мәҗлес барган вакытта миңа аш әзерләү бүлмәсенә чыгарга туры килде. Шунда Таһирның әнисе – Бибинур апаның яшьле күз карашлары белән очраштым.

– Берәр нәрсә булдымы әллә? – дип сорадым.

– Юк, сөенечтән генә... Кодагый белән аңлаша алмыйбыз. Ул – татарча, мин урысча белмим, шуннан гынадыр, – дип елмайгандай итте.

...Янәшәдә, олы мичнең зур казанында, барыбызга да аңлашылганча "гөбер-гөбер" килеп, барлык бүлмәләргә тәмле ис чыгарып, сарык ите салынган аш кайный иде.

Мидхәт САДЫЙКОВ



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 1 (1902) гыйнвар 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 30.12.2020 ел.
Тираж – 3519 Заказ А-3436


Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

16+

Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Кем дә булса социаль ара сакламаса – нишләргә?
2. Мәченең иң беренче кагыйдәсе?
3. Яхшы табиб сүз белән дәвалый диган тәгълимат дөресме?
4. Элеккеге әбиләр белән бүгенгеләренең аермалыгы нәрсәдә?
5. Акыллы хатын тинтәгеннән ничек аерыла?
6. Бер караштан гашыйк булудан иң яхшы чара?
7. Кемнәрне бар ягы да килгән хатын-кыз дип әйтеп була?

ҖАВАПЛАР

1. Шелтә белдермичә, уңайсызланып кына йөткерергә кирәк. 2. Ач булмасаң булма, тик һәрвакыт ашарга сора. 3. Дөрес. Ә хастаханәдә дарулар булган очракта, дарулар белән дә дәвалый ала. 4. Элеккеге әбиләр оныкларыннан энәгә җеп саплауларын сорыйлар иде, ә хәзергеләре "Класс-ташлар"да логин кертүне. 5. Тинтәк хатын ирен тикшереп йөри, ә акыллысы – үзен кайгырта. 6. Тагын бер кат карап алу. 7. Шахматчы хатын-кызларны. Алар сәгатьләр буе сөйләшмичә торалар, фигураларын карыйлар һәм бик күп кызыклы позицияләр беләләр.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 2020 елның 12 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«ИРТӘ ДӘ ГЕНӘ ТОРАМ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
М. НӘРИМАНОВ (Сарман),
Р. ГАЙНЕТДИНОВ (Казан.),
Э. МӘҮЛЕТОВ (Югары Ослан),
Г. ХАННАНОВ (Томск өлкәсе, Вавиловка ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Казаннан **Рафаэль ГАЙНЕТДИНОВ!**



Бәйрәмнән соң...



Валерий ТАРАСЕНКО



Максим СМАГИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



Илдус АЗИМОВ



Илдар НӘФИЕВ

